КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 4 март г.Казань № б-454

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан урманнарда уңайлы санитария-экология хәлен булдыру максатларында:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 22 апреленнән 22 июненә кадәр һәм 9 сентябреннән 9 ноябренә кадәр «Татарстанның чиста урманнары» республика табигать саклау акциясен (алга таба – акция) үткәрү турындагы тәкъдимен кабул итәргә һәм аны акция үткәрү координаторы итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына:

даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, арендага, түләүсез файдалануга бирелгән урман кишәрлекләреннән файдаланучылар белән берлектә, урманнарны каты коммуналь калдыклардан чистарту, корыган агач-куакларны һәм ауган агачларны җыештыру буенча чаралар күрергә;

урман фонды җирләрендә урнаштырылган беседкаларны, мәгълүмат такталарын һәм аншлагларын ремонтларга һәм төзекләндерергә;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникация агентлыгы белән берлектә, республика массакүләм мәгълүмат чараларында акция уздыруны яктыртуны тәэмин итәргә.

3. Республика башкарма хакимият органнарына акциядә актив катнашырга һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар коллективларының урман массивларын каты коммуналь калдыклардан чистарту һәм урман-парк зоналарын тиешле санитар хәлдә тоту буенча эшен оештырырга.

4. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына яшьләр иҗтимагый берләшмәләрен акциядә катнашуга җәлеп итү эшен оештырырга.

5. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы белән берлектә, Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләре территориясендә акция уздыру планнарын эшләүне һәм үтәүне;

акциядә катнашучыларны каты көнкүреш калдыклары полигоннарга чүп чыгару өчен кирәкле транспорт чаралары белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин